РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» июля 2026 ел г. Альметьевск № 1254

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе тарафыннан салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләттерүгә ышанычсыз дип тану һәм исәптән төшерү турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 21 апрелендәге 532 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы карары нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2025 елның 26 мартындагы 02-01-24 номерлы протестын карап,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципальрайоны Башкарма комитетының административ комиссиясе тарафыннан салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләттерүгә ышанычсыз дип тану һәм исәптән төшерү турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» (Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 16 июлендәге 958 номерлы, 2022 елның 22 ноябрендәге 2728 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә,

карарның 1 нче кушымтасында:

2 бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Билгеләнгән вакытта түләнмәгән бюджетка түләүләр (бюджетка түләүләр буенча бурыч), түбәндәге очракта түләтүгә өметсез дип таныла:

а) физик затның - административ штрафны түләүченең үлемен яисә аны Россия Федерациясе граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә

вафат дип игълан иткәч;

б) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, шәхси эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә ул азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә;

в) оешманы - түләүчене оешманың мөлкәте җитмәгәнлектән һәм (яисә) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә аны түләп бетерелмәгән өчен бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә административ штрафны түләүче бетерелгәндә;

г) штрафлар рәвешендә җәзага тартылган яисә суд тарафыннан карар кабул ителгән кешеләргә карата амнистия яисә кичерү турында актлар куллану, аның нигезендә җирле бюджет керемнәре администраторы җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы чыгуга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта;

д) «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән бурычлыга карата бөлгенлек турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау турында карар чыгарылган булса (банкротлык) банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен биш елдан артык вакыт узган;

е) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турында гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителү;

ж) теркәүче орган карары буенча юридик затны юридик затларның бердәй дәүләт реестрыннан төшереп калдыру һәм «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә башкару эшен тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан элек чыгарылган карарның булуы, - Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда оешманың мөлкәте җитмәү һәм аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан түләп бетерү мөмкин булмау сәбәпле җирле бюджетка түләүләр буенча түләнмәгән бурыч өлешендә. Теркәүче органның «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлгә яраксыз дип танылган очракта, элек әлеге пунктча нигезендә түләтүгә өметсез дип танылган бюджетка түләүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерлык) хисабында»;

в) 3 бүлекнең 3.1 пунктындагы подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) җирле бюджетка түләүләр түләү буенча бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында керемнәр администраторының әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтадагы форма буенча белешмәсе;»;

г) 3 бүлекнең 3.1 пунктындагы подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә

билгеләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Регламентында каралган җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында керемнәр администраторы белешмәсе;»;

карарга 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«21» апрель 2020 ел № 532
карары белән расланган
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе тарафыннан салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләттерүгә ышанысыз дип тану һәм исәптән төшерү һәм документларны карау турында карар кабул итү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Габдуллин Илвир Әнәс улы | - комиссия рәисе, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Кәшфетдинова Ләйсән Тәлгать кызы | - комиссия рәисе урынбасары, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы; |
| Щербинина Оксана Анатольевна | - административ комиссия секретаре, район башкарма комитетының муниципаль контроль бүлегенең административ комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча әйдәп баручы белгече |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гыйрфанов Айрат Минзаһит улы | - «Әлмәт муниципаль районының Экология һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе директоры; |
| Аникин Артур Михайлович | - Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад идарәсе башлыгы». |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И. А. Габдуллинга йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.А. Ямалетдинов